СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 1-5 от «18» февраля 2016 г.

Мамадыш муниципаль районының 2015 елда социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2016 елга бурычлары турында

Мамадыш муниципаль районы башлыгы А.П.Ивановның Мамадыш муниципаль районының 2015 елдагы социаль-икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2016 елга бурычлары турындагы хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, Мамадыш муниципаль районы Советы 2015 елда советның эшчәнлеге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләрендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставында билгеләнгән компетенция һәм вәкаләтләр нигезендә башкарылуын билгеләп үтә.

Район эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре булып түбәндәгеләр тора:

- муниципаль районның тотрыклы социаль-икътисадый үсеше өчен алга таба да кирәкле шартлар тудыру;

иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны саклау, милләтара, конфессияара һәм гражданнар татулыгын ныгыту;

- Мамадыш муниципаль районында җирле үзидарәне үстерү өчен кирәкле норматив-хокукый базаны камилләштерү;

- район икътисадын алга таба үстерүгә, муниципаль район халкының лаеклы тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру;

- җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының муниципаль район Советы карарларын һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәвен тикшереп тору.

Югарыда бәян ителгәннәргә таянып, шулай ук Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы, район башлыгының халык һәм Мамадыш муниципаль районы Советы контроле һәм хисаплылыгы турындагы нигезләмәләренә таянып, Мамадыш муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы башлыгы А.П.Ивановның Мамадыш муниципаль районының 2015 елдагы социаль-икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2016 елга бурычлары турындагы хисабын игътибарга алырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Советы депутатларына Мамадыш

муниципаль районы башлыгының 2015 елда Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисади үсеше нәтиҗәләре һәм 2016 елга бурычлары турындагы хисабын үз округларындагы сайлаучыларга җиткерергә.

3. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына тъбщндщгелщрне тәкъдим итәргә:

- хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән бурычларны гамәлгә ашыру буенча чаралар планын 01.04.2016 елга кадәр эшләргә;

- 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының Үсеш Стратегиясе нигезендә стратегик планлаштыру документларын, максатчан программаларны, эшчәнлекнең нәтиҗәләре һәм төп юнәлешләре турында докладларны, икътисад һәм социаль өлкә тармакларын һәм секторларын үстерү планнарын һәм фаразларын әзерләүне гамәлгә ашырырга

-2016-2020 елларга Мамадыш муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш программасын эшләргә һәм расларга, 2016 елда программаның төп бүлекләренең үтәлешен тәэмин итәргә;

- инвесторларны җәлеп итү, яңа производстволар оештыру, муниципаль инвестиция мәйданчыклары һәм җитештерү мәйданнары турындагы белешмәләрне актуальләштерү эшен көчәйтергә, киләчәктә дә Мамадыш муниципаль районы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен максималь уңай шартлар тудырырга;

- республика максатчан программаларының потенциалын актив файдаланырга;

-мәгариф учреждениеләренең, сәламәтлек саклау, мәдәният, физик культура һәм спорт учреждениеләренең матди-техник базасын яхшырту эшен дәвам итәргә, шулай ук күрсәтелгән өлкәләрдә муниципаль хезмәтләрнең иң тулы һәм сыйфатлы күрсәтелүен тәэмин итәргә;

4. Мамадыш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына бюджетның керемнәр буенча планлы билгеләнешләрен үтәүне тәэмин итәргә, шулай ук срогы чыккан кредитор бурычлары барлыкка килүгә юл куймаска.

5. Мамадыш муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына:

- дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен исәпкә алу системасын камилләштерү эшен көчәйтергә;

- дәүләт һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләреннән файдалануның нәтиҗәлелеген, шулай ук муниципаль мөлкәтне һәм җир кишәрлекләрен арендага бирүнең нәтиҗәлелеген арттыру;

- күчемсез милек объектларын һәм җир кишәрлекләрен милеккә рәсмиләштерүгә һәм исәпкә куюга җәлеп итү буенча халык белән оештыру һәм аңлату эшен көчәйтергә.

6. Мамадыш муниципаль районының Контроль-хисап палатасына бюджет акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануга, муниципаль милек белән идарә итүдән һәм эш итүдән алынган акчаларның бюджетка керүенә контрольне көчәйтергә.

7. Мамадыш муниципаль районының авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- авыл территорияләрен комплекслы социаль-икътисадый үстерүгә аерым игътибар бирергә;

-салым базасын төгәлләштерү, крестьян-фермер хуҗалыкларына һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм программаларында катнашуга халыкны җәлеп итү, гаилә фермалары төзү буенча эшләр башкарырга;

- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә игътибарны арттырырга;

- халыкның тормыш дәрәҗәсен киметүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләрдән бертигез дәрәҗәдә файдалануын тәэмин итү чараларын күрергә;

- хокук саклау органнары белән берлектә Хокук бозуларны профилактикалау, террорчылыкка каршы көрәш һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм абруен ышанычлы яклауны тәэмин итү чараларын үтәүне тәэмин итәргә;

- торак пунктларны, зиратларны төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, җирлек территорияләрендә экологик иминлекне тәэмин итү буенча эшне дәвам итәргә.

8. Мамадыш муниципаль районы Советының даими комиссияләре комиссияләр утырышларында әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән чаралар планының үтәлешен үз юнәлешләре буенча карарга тиеш.

9. Әлеге карарны һәм Мамадыш муниципаль районы башлыгының 2015 елгы эшчәнлек һәм 2016 елга бурычлар турындагы докладын Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. mamadysh.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы pravo.tatarstan. ru.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы Рәисе А.П.Иванов